Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ * 2023 * КАЗАН

5

Игорь КИЙКО

КЕМГӘ ҖИҢЕЛ СОҢ ХӘЗЕР, УЛЫМ?!





Алмаз ХӘМЗИН

МАЙЛЫ УЙЛАР...

– Май, дигәч тә, күңелләрдә
Җылы хисләр уяна.
Менә әле бүген дә бит
Хәтер шуны уйлана...

Язның шаулап-гөрләп килгән
Чагы ла ул, лабаса.
Кар эрегән, юллар кипкән,
Тузан – яңгыр юмаса.

Чирәм үскән, яфрак яра,
Яшелләнә агачлар.
Чәчәк ату көнен көтә
Сириннәр, алмагачлар.

Сыерчыклар мәшәкатьтә –
Җим ташыйлар ояга.
Шулхәтле сайрауларына
Ата каз да моңая.

Моңайма, дус, озакламый
Бәбкәң чыгар чирәмгә.
Бикәң тирә тыпырдавың
Китмәгәндер әрәмгә...

Май булып ята күңелгә
Майның һәрбер мизгеле.
Кырда трактор гөрелдәве
Сынала бит күз көне.


Бар иде безнең дә Майда
Шундый шәп матур көннәр.
"Мир, Труд, Май", – диеп йөрүләр,
Күкләргә чөеп гөлләр.

Җиңү көне шул ук айда,
Шатлык яшьләре белән,
Яулап алган безнең өчен
Халкымның көчен күрәм.

Әйе, Майда без дә атлап,
Тыгыз сафларга кердек.
Пионерлар булып илгә
Яңа сулыш өрдердек!

Иген иктек, йортлар салдык.
Тормыш түгел – бал да май.
Әмма күңел саф иде бик –
Бар да тигез – юк бер бай.

Безнең өчен Син һаман шул –
Элеккечә – ягымлы!
Тик чор башка – ягып булмый
Ипигә май, калынны.



Николай ВОРОНЦОВ

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел коллективым, озак еллар эшләвем һәм юбилеем хөрмәтенә мине бик югары инстанциянең Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим итте. Дөресен әйтим, моңа бик күңелем булды... Ләкин аны алу өчен хөкемгә тартылмаган булуым турында һәм түләнмәгән салымнарым булмавы турында белешмәләр кирәк булып чыкты. Менә сиңа мә! Димәк, бер гаилә булып яшәгән коллективыма ышанмыйлар, ә мин үземнең ышанычлы кеше булуымны үзем исбатларга тиеш икән...

Э. Х-ов

КАЗАН

– Ә нигә ЖКХ бурычлары һәм ЮХИДИ штрафлары турында онытканнар? – диде Шомбай ага, укучыбызның хаты белән танышып чыккач. **– Ә иң мөһиме – ир белән хатын бурычы турында!**

Мәхмүт ХӨСӘЕН

ЯШӘРӘМ!

Җитмеш яшькә чыктым быел,
Маңгай тулы җөй генә.
Маңгай тулы җөй булса да,
Йөрәк гел унҗидедә!


Утлы упкыннар узсам да,
Уф дигәнем юк әле.
Бөдрәләрем бәсләнсә дә,
Карашларым ут әле.

Яшьли сөйгән карчыгым да —
Чәчәктәге алмагач.
Майда пешкән пәрәмәчтәй
Яктыра ул, назлагач.

Алтынга тиң алмам барда
Кызыктырмый хөрмәләр.
Җитмештә дә сөю сихри,
Күңел булса күр әгәр.

Керергә һич уйламыйм да
Пропискага картлыкка...
Картайганда яшәрәм мин
Оныкларга шатлыкка!

Валентин ДРУЖИНИН





Александр АЛЁШИН

Тыңлаусызлык бәйрәме

Элекке елларда үсеп килүче буынны тәрбияләүдә ата-аналар гына түгел, ә бөтен җәмгыять катнаша иде. Теләсә кайсы үтеп баручы абый үзен начар тоткан, тәмәке тарткан йә үзенең уйларын әдәпсез сүзләр белән аңлаткан яшүсмерне урынына куя ала иде. Ә инде тегесе кимсетелгән кыяфәт белән әти-әнисенә кайтып зарланса, аңа өендә дә өстәп җибәрүләре мөмкин иде. Мәктәп тә белем бирү белән генә чикләнмичә, бар көчен куеп, баланы яхшылыкка һәм гаделлеккә өйрәтергә тырыша иде.

Хәзер барысы да үзгәрде – үз хокуклары турында әти-әнисеннән дә күбрәк белүче яңа буын үсеп килә. Бу юнәлештә телевидение дә зур булышлык күрсәтә. Билгеле мультфильмдагы "смешариклар", мәсәлән, әти-әниләре аларга ниләр тиеш булуы турында ярсый-ярсый сөйлиләр: "Безнең хакыбыз бар! Без– балалар!" Балалар өчен эшләүче каналларда үз хокукларыңны олылардан ничек яклау турында тапшырулар бара. Ә менә бурычлар турында никтер – ләм-мим. Шуңа күрә дә беренче чиратта балаларның чынлап та катлаулы хәлдә калганнары түгел, ә иркәләнеп үскәннәре "тавыш чыгара". Алар телефоннарын алып куйган, затлы кием сатып алмаган, дуслары белән күңел ачарга җибәрмәгән һәм өй эшләрендә ярдәм итәргә мәҗбүр иткән әниләренә зарлана.

Күптән түгел Мәскәүдә алтынчы сыйныф укучысы мәктәптә дәресләр калдырган һәм өй эшләрен эшләмәгән өчен өендә йомшак урынында каеш татып караган. Нәни әләкче полициягә барып зарланган. Анда укучыга гариза язарга тәкъдим иткәннәр, һәм ул аны рәхәтләнеп язып биргән. Хәзер гаилә башлыкларына җитлекмәгән мокытлары белән судлашып йөрергә туры киләчәк.

Иҗтимагый челтәрләр хәзер тормыш чәчәкләренең әшәке итеп сүгенүе, мәктәптә укытучыларына кул күтәрүе һәм иптәшләрен кыйнавы турындагы видеолар белән тулган. Чыгырыннан чыккан бала-чагага актив рәвештә юристлар һәм психологлар ярдәм итә. Мисал өчен, бер иҗтимагый челтәрдә меңләгән кеше файдаланучы канал бар. Анда балаларга үзләренең хокукларына кул сузган әтиләр, әниләр һәм укытучыларны ничек итеп, нинди статья буенча судка бирү турында җентекләп аңлаталар. Интернет юристы сүзләренчә, мәктәп үзенең эчке кагыйдәләре белән киемгә генә таләпләр билгели ала, ә үсмернең уендагысы – аның шәхси эше. Аның телефонын беркем дә ала алмый, чөнки ул балага бүләк ителгән, һәм ул аның милке булып санала. Ә үзләрен балалар йортына тапшыру белән куркытучы әти-әниләренә зарланучы балаларга юрист ханым ата-ана хокукларыннан үз теләгең белән баш тарту закон белән каралмаган, дип белдерә. Балалар шат, ә ата-аналар югалудан тораташ катып кала. Чөнки алар адвокат ханымның аларга үз балаларын тәрбияләргә комачаулавында һич шикләнмиләр.

Шундый видеодәресләр карап, тагын бер яшь гаделлек өчен көрәшүче аңа компьютер уеннары уйнарга рөхсәт итмәгән өчен, әнисенә зарланган. Ул гадәттән тыш хезмәт номерына шалтыраткан һәм куркынган тавыш белән аны әнисе кыйнады дип хәбәр иткән. Әмма килеп җиткән хокук сакчылары яшь доносчының тәнендә берниди дә кыйнау эзләре тапмаганнар, тик шулай да бу гаилә турында мыекларына чорнап куйганнар.

Ә Түбән Новгородта бишенче сыйныф укучысы мәктәп янында үзен чылбыр белән баганага бәйләп куйган һәм кәнфит таләп иткән, имеш, аның бу татлы продуктны ашарга тулы хокукы бар икән. Яшь протестчыны баганадан полицейскийлар гына аерып ала алганнар.

Заманында зур шау-шу белән 2016 елда кабул ителгән "чәпү" турындагы закон да киң иҗтимагый резонанс тапкан иде. Аның буенча балага чәпеп алган яисә каеш тидергән өчен ике елга иректән мәхрүм ителергә була иде. Күп кенә ата-аналар оештырган петицияләр һәм протестлар үз эшен эшләде, һәм җинаять эшен административ эш дип үзгәрттеләр. Аңа да карамастан, бала хокуклары өчен көрәш барыбер тыңлаусызлык бәйрәменә әйләнде. Әгәр дә элек тәртипсез балалары белән "эшләсеннәр" өчен ата-аналарны мәктәпкә чакырган булсалар, хәзер балалар чиктән ашкан әтиләре һәм әниләрен эшкәртү өчен өйләренә чит кешеләрне чакыралар...

Людмила САФИУЛЛИНА



Игорь КИЙКО

Александр ШУЛЬПИНОВ



Николай ВОРОНЦОВ





• • •

Барысы да дөрес тукланырга куша. Ләкин берәү дә әйтми: акчасын каян табарга?

• • •

Мал табибы терапевтка керә.
Терапевт:
– Нәрсәгә зарланасыз?
Мал табибы:
– Юк, алай бит һәркем булдыра!

• • •

– Сезнең акчага ни теләсәгез, шуны эшлибез!
– Минем акчам ике йөз сум гына...
– Алайса теләкләрегезне тыегыз!

• • •

Әтисе:
– Улым, исеңдә тот: безнең гаиләдә иң баш – мин!
– Ә бу турыда әни беләме соң?!

• • •

– Капитан, минем ике яңалыгым бар.
– Яхшысыннан башлагыз!
– Корабльдә күселәр бүтән юк.

• • •

Суд бинасындагы электр счётчигы котмәгәндә үзенең күрсәткечләрен үзгәртте.

• • •

Элек янгын чыкканда күршеләр үзләренең чиләкләре, багорлары белән йөгереп килә иделәр. Ә хәзер смартфоннары белән. Һәм фотоларны, янгын сүндерүчеләр килгәнче, дөньяга тараталар.

• • •

Хәзергә хәтле аңлый алмыйм, ничек авыртуны баса торган таблетка кайсы төшнең авыртканын аңлый?

• • •

– Пенсиягә чыкканчы ял итеп калырга кирәк.
– Ә нигә?
– Чөнки соңыннан, пенсия акчасы җитмәү сәбәпле, эшләргә туры киләчәк.



Абау!

СОРАУСЫЗ

Татарстанда удар темплар белән төзелгән торак мәйданнарның 74 проценты сатылмыйча ята. Бу күрсәткеч буенча республика Россиядә бишенче урында тора. Һәм бу гаҗәп түгел – гади генә бер бүлмәле фатирның бәясе 6 миллион сум чамасы, ә бу хәтта башыңны ипотека кабаласына тыксаң да һәр кешенең хәленнән килми. Шул ук вакытта фатирлар җитештерү өлкәсендә гаҗәеп хәл барлыкка килде – тәкъдим сораудан артыграк булуга карамастан, бәяләр һаман арта тора. Үзәк банк фикеренчә, Россиядә яшәүче кешегә фатирлык акча җыяр өчен 8 ел буе ашамый-эчми яшәргә кирәк икән. Бу әле исәпләүнең иң оптимистик варианты.

АЛТЫН ТОЯКЛЫ АТЛАР

Казан ипподромы директоры Марат Гыйльфановны нәселле атлар сатып алганда зур күләмле мошенничествода гаеплиләр. Тикшерү органнары фикеренчә, ул югары нәселле чабышкылар өчен субсидия алып, алар урынына гади атлар сатып алган. Ә 9 миллион аерманы үз кесәсенә салган. Өстәвенә, чиновникның мал-мөлкәте күп сораулар тудырган – беркайда да эшләмәүче хатыны белән икесенә аларның 4 фатиры, шәхси йортлары һәм «БМВ Х5» автомобиле бар икән.

ШУЛ УК ТЫРМА

Һәр көн саен 18 дән 65 яшькә кадәр утызлап казанлы, "читтән торып" эшләүче мошенниклар кармагына эләгеп, 2-3 миллион сум югалта икән. Алданган гражданнар саны буенча Татарстан Идел буе Федераль округында беренче, ә Россия буенча бишенче урынны тота. Бу җинаятьнең иң таралган ысулы булып "банк хезмәткәреннән шалтырату" булып кала. Белгечләр кат-кат кабатлыйлар: мондый очракка юлыкканда сөйләшүне өзәргә һәм банкның "кайнар линиясенә" шалтыратырга кирәк.


"АНДЖЕЛИНА"ГА ЯРДӘМ

Казанда яшәүче 19 яшьлек егет, Америка актрисасы Анджелина Джолига эшлим дип уйлап, "акча юу" белән шөгыльләнгән. Ул үзенә җибәрелгән сумманы банкоматларда кәгазь акчага әйләндергән һәм аны "чит ил йолдызының курьерына" тапшырган. Егет моның өчен суммадан 5-10 процент алып барган. Беркөнне аның счётына 950 мең сум төшкән, әмма акчаны алырга маташкан чакта егетне тоткарлаганнар: бу гамәл банкның иминлек хезмәткәрләренә шикле тоелган. Хәзер "Анджелина Джоли"ны полиция эзли.

Михаил ЛАРИЧЕВ



Максим СМАГИН



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

ТЕАТР һәм тормыш

Алар икесе дә театр артистлары иде. Һич тә читенсенмичә, өйләренә кайтышлый рольләрен кабатлап кайтырга булдылар. Пьесаның эчтәлеге нәкъ халәткә туры килә бит...

Язның кояшлы көнендә автобуста аның күзе бер чибәр ханымга төште. "Карале, нинди матур! Танышмый булмас моның белән", – дип уйлады ул.

– Гафу итегез, сезнең янга утырсам буламы?

– Әйе, утырыгыз.

– Танышып китсәк тә буладыр? – диеп, ул сүзен дәвам итәргә кереште. – Сезнең исемегез ничек?

Ханым елмаеп куйды да:

– Фәридә, – дип җавап бирде.

– Менә бит нинди кызык хәл килеп чыкты: сез – Фәридә, ә мин – Фәрит.

– Бәлки язмыштыр бу? – дигән булды ханым.

– Шулайдыр! Мин язмышка бик ышанам. Ерак торасызмы? Сезне озатырга мөмкинме?

– Бик ерак түгел. Озатсагыз була. Мин риза, – дип җавап бирде ханым.

– Фәридә, чыннан да, бик чибәрсез, бер күрүемдә гашыйк булдым.

– Миңа да сез бик ошадыгыз. Гел алай танышып йөрмим транспортта.

– Карале боларга, – диде якында утырып баручы олы яшьтәге хатын. – Хәзерге яшьләрнең бөтенләй оятлары юк. Беренче тапкыр күргән кешесен өенә озаттыра. Бәлки ул бандит яки маньяктыр?

– Юк, маньякка ошамаган. Яхшыдыр, – диде янындагы бабай.

– Әй, күп беләсең инде син. Хәзерге ирләргә бөтенләй ышанырга ярамый. Альфонслар, маньяклар. Кара аны, сумкаңны чәлдермәсен, качырыбрак тот.

Автобуста утырып баручылар игътибар белән Фәрит белән Фәридә сөйләшүен тыңлап бардылар...

– Фәридә, мин сезне бүген ресторанга чакырсам, барырсызмы?

– Һичшиксез, риза.

– Алайса, кичен килеп алырмын да, ресторанга барырбыз.

– Кичкә кадәр көтмәсәгез дә була. Бераздан мин киемемне алыштырып чыгам.

– Аллам, бигрәк тә җилбәзәк инде хәзерге яшьләр, – түземсезләнеп әйтеп куйды арттагылар.

Шул вакыт читтәрәк утырган бер бала болар янына килеп басты:

– Әти, әни, әйдәгез, безнең төшәсе тукталыш! – диде.

Һәм алар өчәүләшеп төшеп калдылар.

Алексей МАМАЕВ



Валентин ДРУЖИНИН



Николай ВОРОНЦОВ





Авто! СТОП!

Александр БРЮХАНОВ

ҖАЙЛЫ КОТЫЛЫШ...

Тормозлар чинаган тавыш таралды, ниндидер каты бәрелү һәм ачы итеп сыгену... Бу хәлне ачыклау мәшәкәте беткәнче, шәмәхәле утларын җемелдәтеп, тагын бер машина килеп туктады.

– Әйдәгез, ачыклыйк, кем гаепле, – дип сүз башлады лейтенант чинындагысы, аннан соң корсагының зурлыгы буенча полковник, үзенең машина капотына учы белән сукты да, авария схемасын сызарга ишарә ясады. – Бәрелешкәнче сезнең машина кайда иде? – диде.

Беренче бәрелешүче капоттагы схемада урынын күрсәтте:

– Менә монда...

– Монысын билгеләп куйыйк әле ничек тә булса, – дип, лейтенант кесәсенә сугып алды. – Бездә аны билгеләү өчен бернәрсәбез дә юк шул, сездә бармы? – диде өстәп.

Зыян күргән зат кесәсеннән бишйөзлек чыгарып, күрсәтелгән урынга куйды.

– Хәзер сезнең машина, – дип, лейтенант икенче бәрелешүчегә борылды.

Тегесе меңтәңкәлекне чыгарды:

– Минеке менә болай бара иде, – диде дә, меңлеген чыгарды. – Ә бу... юлымны кисте.

– Янәшәдән бер джип мине кысмаган булса, – дип ачыклык кертте беренче рульдәгесе һәм джипны меңтәңкәлек белән ныгытты.

– Ә сез берничек тә бәрелешүдән котыла алмадыгызмы? – дигән сорау биреп, лейтенант икенчесенә карады.

– Мин соң ни эшли алам, анда бит машиналар агымы бара, – дип акланды да монысы, агымны тасвирлау өчен йөзлекләр тезәргә тотынды...

– Джипның номерын хәтерегездә калдырмадыгызмы? – дигәндәй, лейтенант бик игътибар белән акланучыга карап торды.

– Юк шул, ул инде борылган иде юл кырыенда җыелган машиналар артына, берни күрерлек түгел, бик тырышсаң да, – шулай диюгә беренче зыян күрүче теге туктап җыелып торучы машиналарны йөзлекләр тезеп тасвирлады.

– Тәк, хәзер миңа юл йөрү хәрәкәте бозылу бик ачык! – диюгә, лейтенант капоттагы акчаларны сыпырып алды да машинасына кереп утырды.

– Ә машинадагы ясалган җимереклек, – дигән ике зыян күрүченең сүзләре хор булып һавада яңгырап калды.

– Аңламадыгыз мәллә, сез, капотта ясаган схема буенча, икегез дә гаепле булып чыгасыз. Үзегез ничек тә булса килешегез... – һәм ул газга басты.

Болар бер-берсенә карашып тордылар да, төрле якка китеп бардылар. Низаг шулай чишелде.

Виталий ПОДВИЦКИЙ



Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО



Виталий ВАВУЛИН



Гөмбәчеләр

Без Байкал күле янындагы бер кечерәк кенә шәһәрдә яшибез. Янәшәдә генә Ябалак тавы, шактый танылган ял базасы – кышын тау чаңгысында, ә җәен табигать кочагындагы рәхәтлекне сөйләп кенә аңлатып, тасвирлап бетерерлек түгел. Бөтен Рәсәйдән туристлар килеп, бу якларны үз итеп бетерделәр, хәтта Мәскәүдән килеп ял итәргә теләүчеләр өзелми.

Күпләренең мәскәүлеләр икәнлеге күренеп тора, бигрәк тә яшьләрнең – алар гел "телефонда" – бөтенләй чын тормыштан аерылганнар. Бервакыт бездән атна буена унөч яшьлек улы белән бер ханым бүлмә алып тордылар. Егет кеше башта көне буе телефоннан күзен алмый йөрде, тора-бара тирә-якка күз төшерә башлады.

Берзаман безнең сөйләшеп утыруыбыздан урманда җиләк-җимеш, гөмбә күплеген ишетеп, болар да гөмбә җыярга уйладылар. Һәм күп тә үтмәде, буш кәрзиннәрен күтәреп кайтып та керделәр. Җиләк ашадык, ә гөмбә тапмадык, диләр.

– Ничек инде гөмбә булмасын?! – дим аларга. – Әнә, күршеләр чиләкләп ташыйлар! Ярар, бераздан бушагач, бергәләп барырбыз...

Бу юлы арыган әнисен калдырып, егет белән икәү киттек. Урманга керүебез булды, үлән арасында – ак гөмбә.

– Әнә! – дим. – Безнең өйдән ерак та түгел – нинди матур! – дип, җайлап кына кисеп алдым. Егеткә карыйм, аптырап, телефонына бакты.

– Ә без әни белән гөмбәне агачтан эзлидек.

Һәм телефондагы фотографиядән каенда үскән гөмбәне күрсәтә.

Гаҗәпләнеп сорыйм:

– Син әллә элек гөмбә күргәнең булмадымы?

– Юк, без бит гомергә Мәскәүдә яшәдек. Шампиньоннар күргәнем бар, супермаркетта.

– Мәктәптә сез алар турында өйрәнергә тиешсез югыйсә...


– Белмим, – ди. – Гөмбәләр белән кызыксынмадым. Бәлки авырган чагым булгандыр.

– Әниең белергә тиеш иде бит...

– Аның Мәскәүдән ары читкә чыкканын хәтерләмим, барсак та Мальдивка яки Төркиягә генә. Сезгә без беренче тапкыр килдек...

Шулай итеп, без аның белән ике кәрзин гөмбә тутырып өйгә кайттык, ә кичен бергәләп кыздырылган гөмбә белән бәрәңге ашадык.

Соңыннан малайның үз гомерендә якыннан сыер күргәне булмаганын да белдек, кәҗәне дә – зоопаркта гына. Ял көннәренең ахырына хәтле ул гөмбә җыярга яратучы, табигатьне сөюче иң күркәм кешегә әверелде.



Сергей АНДРИАНОВ

Абау!

НӘТИҖӘЛЕ ШАЯРУ

Санкт-Петербургта хокук саклау органнары хезмәткәрләренә тагын бер мыскыллаучы эләккән. Иптәшләреннән аермалы буларак, Новороссий шаяртучысының шаярулары бөтенләй зарарсыз булмаган. Бу кеше, югары идарә исеменнән, дәүләт хезмәткәрләреннән акча алган. Ул алдауга җаваплы караган: хакимият структурасын һәм түрәләр тавышы язылган аудиоязмаларны җентекләп өйрәнгән. Шаярулар барып чыккан, шуңа күрә шаяртучы хәзер суд карарын көтә.

СИСТЕМА УҢЫШСЫЗЛЫГЫ

Свердловск өлкәсендә хатын-кыз эшкуар салым системасын тетрәткән. Шулай бервакыт даруханәләр хуҗасына декларация бирү вакытын бозган өчен 500 сум штраф салганнар. Ләкин эшкуар хатын, үзенең гаепсезлегенә ышанып, принцип буенча эшләгән һәм салым бүлеген судка биргән. Судья эшкуар ягына баскан һәм штрафны юкка чыгарган. Җиңүеннән илһамланган хатын-кыз салым органнарыннан әхлакый зыянны һәм юридик чыгымнарны каплауны таләп иткән. Бу юлы да суд шулай ук дәгъвачы белән килешкән һәм Федераль салым хезмәтенә салым законсызлыгы корбанына 70 000 сум түләргә кушкан. Ә кырда берүзең генә сугышчы түгел диләр тагын!

ЭТЛӘРДӘН ШАУРМА

Курск өлкәсенең Карл Либкнехт поселогы башлыгы Александр Туточкин адашкан этләр белән хәзерге хәлдән чыгу юлын тапкан. Монда яшәүче берәү эт көтүенә булган моң-зары белән администрациягә килгәч, ул оригиналь бизнес-план тәкъдим иткән. Башлык, проблеманы иң яхшы чишү – эт ите белән тутырылган шаурма сату кибете ачу булачагын әйткән. «Сез миңа булышачаксыз, һәм үзегезгә дә керем булачак», – дип нәтиҗә ясаган түрә.

КӨЙСЕЗ ФОРТУНА

Мәскәүдә яшәүче 50 яшьлек кеше, лотереяда җиңеп, финанс хәлен яхшыртырга булган. Ләкин билет сатып алу өчен акча сарыф итмәгән, аларны сатучы булып эшкә урнашкан. Рәсми позициясеннән файдаланып, ул 1,4 миллион сум күләмендә 12 мең лотерея билетын үзенә алган. Билетларның берсе дә җиңүле булмаган. Фемида, Фортунадан аермалы буларак, сайлап тормаган – элеккеге сатучыга 10 елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү яный.

Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Ринат АБЗАЛОВ



Виктор ВЕСЕЛОВ

Астрологик тәҗрибә

Бакчада эшләр башланып чак җиткәч, хатын яңа фикер кертте. Без дөрес эшләмибез икән. Гороскоп буенча яшәү бик тә уңышлы булуын бакчадагы күршеләрдән белгән. Тегеләр һәр адымнарын йолдызлар аша чутлыйлар, барлык үсемлекләрне ай календаре буенча утырталар ди. Шуңа күрә безнең бәрәңгеләр рогаткага куеп атарга гына яраклы икән, ә аларныкы ике төптән – бер чиләк.

Мин хатынга аңлаттым, без үзебезнең "борчакларны" үзебез җыеп алабыз. Кемгә кирәк алар? Ә күршеләрнең ул шаккаттыргыч уңышларын инде бишенче ел рәттән урлыйлар, сабаклары гына кала. Компост өчен ярый инде, ләкин хатын белән бәхәскә керү файдасыз. Ярар, астролог календарен кулланып яшәрбез. Берочтан йолдызлар алдамый икәнлеген дә белермен.

Дүшәмбе. Миңа гороскоп буенча "бик тә шәп компания белән аралашу" куелган, ә хатынныкына – "табигатьтә булу". Әйтәм моңа: "Җыен да бакчага бар. Җир инде җылынган, бәрәңге утыртырга вакыт. Ай вакыты буенча шулай. Берочтан күзәнәкләрен алып барырга да кирәк. Ике генә капчык булса да. Хәзер автобуслар яхшы йөри". Ул мине "әйбәтләп" ачуланды, ләкин китте. Ә мин яхшы гына аралашу өчен мужиклар янына гаражга киттем.

Сишәмбе. Иртән, кичәгедән соң кәчкә аңга килеп, гороскопка төбәлдем. Ышанмассыз! Минем тагын "шәп компания белән аралашу". Хатынныкы – "табигатьтә булу". Бер уйласаң, бер дә начар түгел. Вакыты шундый: бер көн елны туендыра! Хатынга гороскопны күрсәтәм. Ул кычкыра: "Аны синең кебек алкаш төзегән!" – ди. Нишләсен, китте инде. Мин күрше хатыны янына кереп киттем. Гороскоп турында сөйләдем. Бурычка баш төзәтергә алдым. Күршем кызыксынып: "Карале, гороскоп буенча минем нәрсә икән?" – дип сорады. Анда язылган: "Озакка ялгыз калмагыз". Көлде рәхәтләнеп: "Әгәр дә ирем моны укыса, балыкка ике аягының берсен дә атламас иде!.."

Чәршәмбе. Уянуыма, хатыным инде юк иде. Өстәлдә язу калдырган: "Кадерле Кәҗәмөгез! Мин бакчага киттем". Гороскопка карасам, анда: "Берәүгә дә ышанмагыз, сезне алдарга мөмкиннәр". Ә хатынныкы: "Үзегезнең тормышны корыгыз. Кемне яратасыз, шуңа булыгыз". Чаптым дачага. Хатынны эзлим. Карыйм, ул анда быел әле бер тапкыр да булмаган икән. Бүген өйгә дә кайтмады...

Пәнҗешәмбе. Иртән иртүк күршем керде. Ул ресторанда повар булып эшли. Миннән тапалган ит ясады... Кәчкә караватка барып яттым. Күздән утлар чыкты, әмма гороскопны укый алдым. Бу көнне миңа болай дип язылган: "Үзегезне куркыныч хәлгә куймагыз, сәламәтлегегезне саклагыз" диелгән. Күршегә "батыр булырга" кушылган. Ул аны күрсәтергә өлгерде инде...

Җомга, бер ай үткәч. Астрологик тәҗрибә ахырына якынлашты. Бүген хастаханәдән чыгачакмын. Соңгы мәртәбә гороскопка карадым. Инде булганыннан начаррагы килеп чыкмас. Миңа: "Файдалы уңышлыклар" дип күрсәтелгән, ә хатынныкы: "Мәрхәмәтлерәк булыгыз!" – диелгән.

Шулай да йолдызлар алдамый. Төштән соң хастаханәгә хатын килде. Чыгуым белән котлады һәм култык таягы бүләк итте. Яңа иреннән икән.

Александр ШУЛЬПИНОВ



Михаил МИХАЙЛОВ

БИК ШӘП

– Төзелеш ничек бара?

– Барысы да план буенча!

– Сметадан чыкмадыгызмы?

– Бераз гына...

– Ә төгәлрәк?

– Ике тапкыр...

– Сроклар буенча артка калмыйсызмы?

– Әзрәк бар инде...

– Ә төгәлрәк?

– Бер елга...

– Бу халне тиз генә төзәтер өчен, чараларын күрегез!

– Күрдек инде!

– Ә төгәлрәк?

– Смета буенча чыгымнарны өч тапкыр арттырабыз. Төзелешнең срокларын шулай ук өч тапкырга озайтабыз...

– Бу гына җитми!

– Объектны алданрак тапшырабыз!

– Ә төгәлрәк?

– Билгеләнгән срокка караганда, бер атнага иртәрәк!

– Ярый, шәп!



Николай ВОРОНЦОВ

Дамир БӘДРИЕВ

Шакшука

Туганыбыз бик тә үтенеп кунакка чакыргач, хатыным белән шәһәргә кузгалдык. Үзебез белән күчтәнәчкә, эченә җимешләр, алмалар, лимоннар тутырып пешерелгән каз һәм бер чиләк күкәй алдык.

Казаныбыз матур инде, әй! Урамнарны, кибетләрне карап йөргәндә туганыбыз кәрәзле телефоннан шалтыратты.

– Анда ашханәләргә кереп акча туздырмагыз. Төшке ашка пашот әзерләп куям, – ди.

Ишеткән нәрсә түгел, хатыным белән икебезнең дә авызлардан сулар китте. Кайтып, өстәл артына утырсак, "пашот" дигәннәре сытылган күкәйне полиэтилен пакетка салып, кайнар суда пешерү икән. Икенче көнне музейларны карап йөргәндә янә туганыбыз шалтыратты.

– Анда ашханәләргә кереп акча туздырмагыз. Төшке ашка скрэмбл әзерләп куям, – ди.

Ишеткән нәрсә түгел, хатын белән икебезнең дә авыздан сулар китте. Кайтып, өстәл артына утырсак, "скрэмбл" дигәннәре табада өстен каплап пешерелгән күкәй тәбәсе икән.

Өченче көнне театрга бардык.

– Анда ашханәләргә кереп акча туздырмагыз. Кичкә шакшука әзерләп куям, – дип әйтеп калды туганыбыз.

Ишеткән нәрсә түгел, хатыным белән икебезнең дә авыздан сулар китте. Ниһаять, шашлык белән шулпа була икән, мин әйтәм. Кайтып, өстәл артына утырсак, "шакшука" дигәннәре помидор яки борыч турап, табада кыздырылган күкәй икән.

Әй кыстый туганыбыз, әй кыстый.

– Абау, өстәлгә мангольд чыгарырга онытканмын икән, – дип, аш-су бүлмәсенә йөгерде.

Ишеткән нәрсә түгел, хатыным белән икебезнең дә авыздан сулар китте. Шашлыкларны мангалдан алып керә бугай дип уйладык. "Мангольд" дигәннәре чөгендер яфрагы туралган салат икән. Бу салатта сыр кисәкләренә караганда, яшел яфраклар күбрәк.

– Кибетләрдә итләр, колбасалар юкмы әллә соң? – дип әйтеп куйдым, телемне тыймыйча.

Туганыбыз шул ялгыш ычкынган сүземнән соң, итнең организмга зыяны турында бер сәгать лекция укыды. Аерым бүлмәгә кереп йокларга яттык.

– Шакшукаларын штукатурить итим. Монда иртән дә, кичен дә күкәй ашап, тавык кебек кытаклый башлыйбыз хәзер. Таң беленүгә өйгә кайтып китәбез, – дип, хатынымның колагына пышылдадым.

– Нәкъ авызымнан алып әйттең. Баскан токмачлы ашларыбыз, итле бәлешләребез сагындырды, – дип, кочагыма сыенды хәләл җефетем.

Авылга кайткач, күрше-күлән: "Ничек кунак булдыгыз?" – дип кызыксына.

– Байлар гына ашый торган пашот, скрэмбл, шакшука, мангольд, балоньеза һәм карбонара пасталары белән сыйландык, – дибез.

Ишеткән-күргән нәрсәләре түгел бит, авызларын чәпелдәтеп тыңлый күршеләребез хатын белән икәүләшеп мактанганны. Кеше көлдереп өч көн буе күкәй белән макарон ашаганны әйтеп булмый бит инде.

Зәки НУРИ

МИН ҮЗЕМ СӘЕР ИКӘН...

Мин үзем сәер икән...
Сиздем, дуслар, сәгатемнең,
Сиздем сәер гадәтен;
Сиздем сәер гадәтен мин –
Соңга кала сәгатем.

Ни дип тә әйтергә белмим,
Ни булды, нәрсә сәбәп:
Тибешеннән йөрәгемнең
Ник артка кала сәгать?

Йөрмидер кебек телләре,
Карыйм да кабат борам.
Очрашу көткән көннәрне
Гел шуңа карап торам.

Сәер ашкыну бар миндә –
«Көтәм!» дигәндә иркәм,
Сәгатем соңгарып дим дә,
Өч сәгать алдан китәм...

Сәгатьне юкка борганмын,
Аңлатты, хәер, иркәм:
Үләрдәй гашыйк булганмын,
Мин үзем сәер икән...

Хафиз ГАЛИЕВ

БОЛАН ТҮГЕЛ

Берәү сөйли: Башка кеше белән
"Мөгез" куя икән сөяркәм...
Горур калып, аны ташлыйм мәллә,
"Болан" булмыйм микән кичерсәм?
Шунысы бар, тик мин генә түгел,
"Болан" булып чыга "баҗа" да,
Икенчедән, әллә ни зарар юк –
"Өлеш" тия барчабызга да!
Ә мин әйтәм: Хафаланма, дускай.
Сөяркә "мөгезе" саналмый.
Үз хатының сиңа тугры калса,
Андый кеше "болан" булалмый!

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Гигиена фәне үз сәламәтлегеңнең чылбыр эте булырга өйрәтә.

Кешенең яшьлеге юләрлекләр эшләргә курыкмавы белән үлчәнә.

Җитәкчелек итү – ул булдыклы кешеләргә эшләргә комачауламау.

Картлар тумый, ә үлә генә. Ләкин, аңа карамастан, аларның саны арта тора.

Туры юл – ул ике күңелсезлек арасында иң кыска ара.

Ахмакларның ике төре була: беренчеләре бөтен кеше аңлаган нәрсәне аңлый алмый, икенчеләре беркем дә аңламаган әйберне аңлый.

(Акыл иялəре мәҗлесендә язып алынды)



Валентин ДРУЖИНИН

ҮЗЕ ШУНДА ИДЕ

Халкыбызның, миллатебезнең сөекле улы, моң чишмәсе, классик җырчыбыз Эмиль ага Җәләлетдиновның чыгышын миңа Мәскәү шәһәренең Эстрада театры сәхнәсендә тыңларга насыйп булды, ул бу концертта халкыбызның "Зәңгәр күз" исемле әсәрен симфоник оркестрга кушылып башкарды. Аның осталыгын сәхнә кырыенда сокланып тыңлап тордым. Әле яңа гына хәрби хезмәттән кайткан яшь музыкантка, бик тә көчле йогынты ясады, уңай тәэсир калдырды. Консерваториядә укыган елларым искә төште: менә аның басып торулары, тавышының яңгырашы, башкару осталыгы, әсәрнең эчтәлеген ача белүе... Зыялылык! Бу терминнарны теоретик яктан гына белә идем. Ә бүген алар – башкала сәхнәсендә. Җырчыбыз көчле алкышларга, чәчәк бәйләмнәренә күмелде...

Тумышы белән Сәмәркандтан булган, үзбәк, рус һәм башка милләтләр арасында үскән егетнең татарчаны камил һәм төгәл белүе – фәкать үзенең тырышлыгы нәтиҗәсе.

Бервакыт концерттан соң автобуста Казанга кайтабыз. Ара шактый ерак. Шунда Эмиль абый Тукайның "Кисекбаш"ын, шагыйрьнең үзе әйтмешли, нәкъ безнеңчә милли, моңлы итеп саф татарча, бер дә ялгышмыйча яттан сөйләп чыкты.

Консерватория тәмамлаган югары белемле классик җырчы, башка милләт әсәрләрен дә бердәй тигез күрә, берсен дә ят итми. Ул тагын сигез телдә: инглиз, француз, алман, итальян, грузин, таҗик, үзбәк, казакъ җырларын югары осталыкта башкара. Аның репертуарында вокал-камера әсәрләре, татар композиторлары – Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Монасыйпов, Ж. Фәйзи, М. Мозаффаров, А. Ключарёв, Р. Еникиев, М. Яруллин әсәрләре булды.

Кешелек сыйфатларын да әйтеп китәм. Эмиль абый бик тә тәртипле, тәрбияле, югары зәвыклы, эчке культуралы эрудит кеше иде. Беркайчан да беркем белән дә ызгышмады, талашмады. Үз эшен белде, үз сукмагыннан барды, ләкин тамашачылардан, коллегаларыннан аерылмады, гел янәшә атлады.

Сөекле җырчыбызны соңгы юлга озатканда Алмаз Хәмзин белән бергә басып тордык. Халыкка комачауламыйча, шыпырт кына сөйләшәбез. Кремльдән вәкилләр (җитәкчеләр) бармы? Күренмиләр. Мин дә күрмим. Ә мәдәният министрлыгыннан? Берәү бар. Шөкер. Ә яшь җырчылар? Берсе дә юк, "Йолдыз"ларның аска төшкәнен кайчан күргәнең бар? Алар фонограмма язылган такмаклары белән үз казаннарында кайныйлар, акча саныйлар. Бу хакта бер студентым болай ди: "Кирам абый, менә бу җырчы дүрткә кадәр саный белми, унбиш мең сорый". "Ә Эмиль абыең беркайчан да акча сорап вакланмады, бушка да җырлап китә иде кайчагында, халкы өчен", – дидем аны шаккаттырып.

Баянга кушылып җырлый ала торган артистларыбыз аз. Юк дәрәҗәсендә. Күптән түгел Мәскәүдә, аннары Уфада Р. Ваһапов исемендәге фестиваль кысаларында Татарстан артистларының зур концертлары булып узды. Сигезенче дистәсен күптән ваклаган Алмаз абыйлары "живьём" җырлаганда, ничек инде Г. Фарукшин, А. Тимершаех авыз ачып торсыннар! Оялмыйча! Җырладылар, ә мин – шулар яшендәге "егет" – рәхәтләнеп уйнадым... Элек тә Илһам Шакировка да, Эмиль абыйга да уйнаган музыкант әле абзагыз!

Хәзерге "йолдыз"лар бүгенге тормыш караңгылыгында ныграк балкый сыман... Ләкин Эмиль Җәләлетдинов хакыйкатьне белеп китте, чөнки үзе шунда иде...

Кирам САТИЕВ,
Татарстанның халык артисты.



Борис СТАРЧИКОВ, «Чаян», 1964 ел.



Эрнст ГЕЛЬМС, «Чаян», 1969 ел.





• • •

Зарарлы эштә эшләгән өчен сөт кенә бирү җитми дип исәплим, шуңа күрә кайберәүләргә селёдка өстәп, аны нығытырга дигән карарга килдем.

• • •

СССРда секс булмаган, ләкин һәр гаиләдә икедән алып дүрткә һәм күбрәк тә бала туган. Хәзер секс бар, әмма гаиләләр бер генә балалы. Нәтиҗә: балалар секстан тумый. Ләкләкләр кирәк микәнни?..

• • •

Бәяләр күтәрелү – борынгы урыс уены.
– Ләкин бит Сталин вакытында бәяләр төшкән...
– Ул чакларда уен кайгысы булмаган.

• • •

– Ни өчен син теш табибы булырга теләдең?
– Ә миңа ир-атларның авызларын ачып, күзләрен шар итеп карап торулары бик ошый.

• • •

– Кадерлем, өйгә кергәч тә ишек төбендә нинди бүләкләр тора ул?
– Кагылма аларга! Ул безнең ризык пешерүчегә, җыештыручыга һәм бала караучыга!
– Бездә бит андый кешеләр юк.
– Ничек булмасын? Ә мин?!

• • •

Яшәгән ди карт белән карчык. Карчыгы картына әйтә:
– Картым, бездә балалар булачак бугай...
– Ничек булмасын ди! Иртәгә пенсия алабыз бит!


• • •

Кибет челтәрләренең күбесендә ашамлыкларга мондый аңлатма язып куйсалар комачауламас иде: "Кулланыр алдыннан табиб белән киңәшеп алу мәҗбүри!" дип.

• • •

– Мин дүшәмбе көннәрендә үземне Робинзон Крузо кебек хис итәм.
– Нигә?
– Җомганы сагынып.

Валерий ТАРАСЕНКО







КИЛЕШМӘГӘН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Хөрмәтле «Чаян»! «Юләр күпер янында да сай урын эзләр», – диләр халыкта. Ә менә без, ЗЯБ һәм Элеватор тавы бистәләрендә яшәүчеләр, моның белән ризалаша алмыйбыз. Үзебезне юләр дип санамасак та, күпер була торып елганы кичәр өчен башка юллар эзләргә туры килә. Үзегез уйлап карагыз. Җиде ел элек безнең бистәләр арасында Мәләкәс елгасы аша череп беткән иске агач күпер яңасын төзеп куйдылар. Бу – ике төбәкне ялгап торучы бердәнбер юл. Имештер, аны герман технологиясе буенча, барча экологик нормаларга туры китереп төзегәннәр. Ләкин корылма бары тик биш ел тора алды – безнең җиргә чит ил технологияләре килешмәгән, күрәсең. Үзебезнең ысуллар белән аңа ремонт ясарга туры килде. Кешеләргә уңайлы булсын өчен хәтта лифт та ясап куйдылар. Дөрес, аның эшләвен беркем дә күрмәде, ә бер-ике елдан яңадан җимерелә башлады. Бәлки, шулай да эш монда технологияләр түгел, ә бирелгән акчаны үзләштерүнең җирле үзенчәлекләрендәдер?

ЗЯБ һәм Элеватор тавы бистәләрендә яшәүчеләр.
ЧАЛЛЫ

САСЫ ИНЕШ БУЕНДАГЫ САНДУГАЧ

Кадерле редакция! "Сандугач урманы" "(Соловьиная роща") торак комплексында Рәүис Гәрәев урамындагы 102 нче номерлы йортны сатып алганда кызыксындыргыч вәгъдәләр күп булды: экологик яктан чиста район, тыныч урын, киң инфраструктура һәм хәтта яз көне сандугачлар сайравы. Асылда, алдамадылар шикелле, әмма гүзәллекләр бөтенләй көтелмәгән яктан килеп чыкты...

Менә инде берничә ел йорт канализациясе кеше тормышының калдыкларын тулысынча кабул итә алмый. Сасы инешләр даими рәвештә асфальт өстенә ургылып чыга. Башта бер генә люктан аккан булса, хәзер инде бишесеннән дә. Балаларны урамга чыгару да куркыныч – берәр нинди авыру эләктерүләре бар. Дымлы һава аркасында йортта бөҗәкләр барлыкка килде. Ә фундаментның нинди хәлдә булуын күз алдына китерүе кыен түгел...

Җирле идарәчеләр һәм «Водоканал» бу мәсьәләне әллә хәл итә алмыйлар, әллә теләмиләр. Бу аңлашыла да – сасы инеш өстендә яңгыраган сандугач сайравы аларга барып җитми, күрәсең...

Н. ХИСАМОВ
КАЗАН

Валентин ДУБИНИН



Василий АЛЕКСАНДРОВ





Шагыйрь Мөхәммәт Садри (Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов) 1913 елның 20 (31) маенда Казанда Яңа бистәдә туган. Әти-әнисе вафат булгач, балалар йортында тәрбияләнә, 1928 елда ФЗӨ мәктәбендә укый.

Заводта эшләгәндә М. Садри каләм тибрәтә башлый. Аның газета-журналларда басылган шигырьләренә Хәсән Туфан игътибар итә һәм 1932 елда яшь шагыйрьнең "Жыр башлана" дип исемләнгән беренче китабы дөнья күрә. Шул ук елда аның бер бәйләм шигырьләре Мәскәүдә М. Җәлил тарафыннан төзелгән "Чакыру" җыентыгына кертелә.

1932 елда М. Садрины Мәскәүгә укырга җибәрәләр. Уку белән бергә, М. Садри ул вакытта Мәскәүдә яшәгән татар әдипләре белән якыннан аралаша, М. Җәлил җитәкчелек иткән журналның әдәбият-сәнгать бүлеге эшләрендә актив катнаша.

1935 елда институтны тәмамлап кайткач, шагыйрь берничә ел административ эштә эшли, аннары фольклор экспедицияләрендә катнаша, Агыйдел, Иртыш, Тобол буйларындагы авылларда, Ом, Том, Төмән шәһәрләрендә булып, куплаган татар халык җырлары һәм әкиятләре язып кайта.

1941 елның җәендә М. Садри Бөек Ватан сугышы фронтына китә. Аны А. Фадеев рекомендациясе белән татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясенә хәрби корреспондент-оештыручы итеп җибәрәләр. Фронт газетасында шагыйрьнең совет сугышчыларын җиңүгә рухландырган дистәләрчә очерклары, патриотик шигырьләре, сатирик әсәрләре басыла.

Ватан сугышыннан соңгы тыныч төзелеш елларында М. Садриның әдәби иҗаты аеруча активлаша. Ул поэмалар һәм йөзләрчә шигырьләр, җырлар иҗат итә. Аның татар композиторлары тарафыннан музыкага салынган күп кенә җырлары киң популярлык казана. Шагыйрьнең шулай ук рус һәм башка тугандаш милләт шагыйрьләреннән эшләгән поэтик тәрҗемәләре дә шактый.

Мөхәммәт Садри Бөек Ватан сугышындагы батырлыклары өчен — Кызыл Йолдыз ордены, сигез медаль, ә әдәбият өлкәсендәге хезмәте өчен «Почет Билгесе» ордены һәм күп кенә Мактау грамоталары белән бүләкләнгән. 1983 елда, җитмеш яше тулу уңае белән, аңа РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

М. Садри 1939 елдан СССР Язучылар союзы члены иде.



МИН БЕРЛИННЫ АЛДЫМ

Юаш кына малай идем,
Чебен дә үтермәдем,
Усал кеше булырмын дип,
Уйга да китермәдем.

Ярата идем шау-шулы
Язгы сабан туйларын,
Мәш килгән кырмыскаларны,
Яшел Идел буйларын.

Осланның тавына менеп,
Иделгә карый идем,
Пароходлар, көймәләрне,
Салларны саный идем.

Иртән үк Идел өстеннән
Таралып беткәч томан,
Күренә иде Казаным
Миңа зур завод сыман...

Сокланып күзәтә идем
Ял иткән минутларда
Ак күбәләкләр очуын
Зәңгәрсу болытларга...

Балалар йортыннан чыккан
Бер юаш бала идем,
Үлгән песине күрсәм дә
Гаҗәпкә кала идем.

Үзгәреп киттем кинәт мин:
Булдым ут, булдым болыт,
Яшеннәр кебек яшьнәдем,
Күкрәдем күкләр булып.

Якладым Мәскәү җирләрен
Янар утларга кереп,
Җан тетрәде фашист дигән
Шакшы ерткычны күреп.

Дошманга утлар яудырып,
Сугышта усалландым,
Әсир һәм кол булмас өчен
Берлин каласын алдым.

«Казан» исемен язып куеп
Рейхстаг диварына,
Ашкындык танк өстендә
Прага юлларына.

Җиңеп кайттылар Иделнең
Ир-егет агайлары;
Сезгә булсын якты дөнья,
Илебез малайлары.

Курку белмәс солдат булдым
Дошманның өннәрендә...
Тагын-тыныч төзүче мин
Туган як җирләрендә!

САЙРА, САНДУГАЧ!

Сайра, сайра, сандугачым,
Талдан талларга очып,
Күңелең теләгән җиргә очып,
Матур чәчәкләр кочып.

Сандугачым сайрый чут-чут, дип,
Безнең илдән матур ил юк, дип.

Сайра, сайра, сандугачым,
Бездә шат тормыш көлә,
Бездә, матурлап синеңчә,
Бар халык җырлый белә.

Сандугачым сайрый чут-чут, дип,
Безнең илдән матур ил юк, дип.

Сайра, сайра, җырчы кошым,
Җырла бер дә армыйча.
Җир шарын шау-гөрләтеп без
Җырлыйк бертуктамыйча.

Сандугачым сайрый чут-чут, дип,
Безнең илдән матур ил юк, дип.

БЕР САТУЧЫ ХАТЫННЫҢ БАЛА ТИБРӘТКӘНДӘГЕ ӨМЕТЛӘРЕ

(Г. Тукайга ияреп)

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәктәпләргә китәр бу,
Әлифбаны өйрәнеп,
Мөдир булып китәр бу.

Магазинда эшләр бу,
Әйбәт кием кияр бу;
Майда гына йөзәргә,
Ферма кызын сөяр бу.

Таныш-белеш табар бу,
«Мәскәвский» кабар бу.
Кибеттәге мал белән
Үзен-үзе карар бу.

Сый-хөрмәтләр күрер бу,
«Волга» белән йөрер бу,
Товарларның яхшысын
Арттан гына бирер бу.

Собраниегә барыр бу,
Премия алыр бу,
Һәркемне шаккаттырып
Зур гына йорт салыр бу.

Мөдирем, кибетчем бу,
Шикәрчем бу, итчем бу,
Куанычым, шатлыгым,
Бу, бу минем, бу, бу, бу!..



«ЧАЯН» – КУАНЫЧЫБЫЗ!

Матбугат басмаларының тиражы кими дип зарланып утырасым килми. Язмышлары шундый: чорына, җәмгыятенең торышына бәйле сәбәбе. Гәрчә, кеше дигән феноменның, асыл затның әһәмияте кирәк саналса, ул алай булмас иде. Кайберәүләрнең – үзләрен Алланың Кашка тәкәсе итеп чутлап йөргән бәндәләрнең фикер сөреше камил юнәлештә булса, без мондый хәлгә калмас идек, дигән калыпта мин. Алар өчен Аллаһы Тәгалә дә авторитет түгел, хәер, акча-байлык күпертүдә Аның исеме ярдәм-йогынты ясаса, әүлиялыгын кулланудан тартынмаслар иде һәм тартынмыйлар да!

Ярый, монысы кереш сүз булды. Шулай да, җәмәгать, матбугат белән арагызны суытмагыз, үзмәгез сез киң сулышлы яшәешегезне дөньялыктан, тулы хакыйкатьтән, дөресне ялгыштан аера белүдән, актив тормыш юнәлешеннән. Үзегезнең мохитегезгә күз салыгыз әле: бармы янәшәгездә киңәшер, фикер алышыр дусларыгыз? Үзгәрешләр, яңарышлар табарлык сүзләрегез – кайдан белдегез, күрдегез, укыдыгыз аларны – бүлешегез куанып шуларны һәркем белән! Ямь таба – тоясызмы? Чыганаклары өстәлегездә яздырып алынган газета-журналларданмы? Әйтсеннәр үзеңә: "Син ничек шулай яшь күренәсең? Югыйсә диңгезләргә барып, су коенып та йөрмисең бугай бит?!" – дип. Әйт: "Мин бит күп итеп газеталар яздырып алам!" – диген. – Укыйм, шундагы язмаларны анализлыйм, анда матур яшәүче, хезмәт куючы кешеләр турында язалар!" – дип сөйлә. Уртаклаш белгәнеңне!

"Чаян" журналы алдырам", – диеп мактан. Дөрестән дә алдырасың икән, коры куаныч булмыйсың. Кешеләргә уңай тәэсир ясa! "Чаян" журналы ул – һәр стресска смехотерапия сыман сихәт, дәва бирә торган үзенчәлекле басма! Кайгы-сагышларны җиңел кичерергә ярдәм итә, һәм дә юмор хисен көчәйтүдән тапкырлыкны арттыра, җор телле буласың – андый кеше начальниклар янына кергәндә ишеге төбендә калтырап тормый инде. Үз йомышын үтәп чыга, аның юмалавына алданмый… Белдегезме, җәмәгать! Бу катлаулы чорда "Чаян"га язылу бик тә мөһим! Бурычыгыз дип санагыз! Ул сезнең иң якын киңәшчегез, ярдәмчегез булыр!

Алмаз ХӘМЗИН

УҢАЙЛЫКЛАР ТУДЫРУ – ҮЗ КУЛЫБЫЗДА!

Аңламассың бу дөньяны… Кызык та, кызганыч та… Дөрес тә, дөрес тә түгел… һәм башкалар…

Хастаханәдә яттым – терапиядә. Коридоры тулы гөлләр… Терелмәс җирдән терелерсең… Һавасы саф, матурлыкка, гүзәллеккә сокланып, үзеңнең барлыгыңа куанып йөрисең, тынычланасың. Күңел юатырдай музыкасы да яңгырый бит әле. Кеше өчен, аның сәламәтлеген кайгыртып эшләнгәненә хәйран калып сөенеп куясың. Кая монда авыруыңа ыңгырашып йөрү – онытыла барысы да. Бар бит шундый чаклар, әйтик, теш сызлап стоматологиягә баруың һәм табиб кабинеты янына килеп утыруың була – туктый. Әйе, әйе, шулай – кире кайтып китәрдәй хәлгә киләсең. Йә булмаса шундый врачка эләгәсең – аның тәмле теленә сихерләнеп, чирең онытыла. Теш мәсьәләсендә генә түгел, бүтән чакларда да. Мәкале дә бар: "Тәмле тел – җанга шифа!"

Әле менә эштә дә шулай безнең – өстәл артында гына утырып хезмәт куйсак та, үзебезнең сәламәтлегебез турында кайгыртабыз. "Хәрәкәттә – бәрәкәт", диләр бит. Ә ул безгә бик зәкми. Нишлисең – эзләп алган язмыш. Ләкин чарасын табабыз: тәрәзә төпләрендә гөлләр үстерәбез. Аларның чәчәк аткан чакларын күрсәгез, ул язга таба тартмадагы туфракка суган төртеп, кыяк үстерүләр! Врачларга шуны сөйлим дә, шулхәтле көчле яклау табам! "Шулай кирәк! Молодцы!" – диләр. – "Авитаминоз булмасын өчен иң кирәкле һәм җайлы ысул!" – дип, күңелне үстерәләр. Иммунитет ныгытуга да файдасы зур бит аның, язгы чорда бигрәк тә. Шуңа күрә җитәкчелегебез безнең бу башлангычыбызны бик тә мактап тора. Әле һәр эш бүлмәсендә "гөл бакчасы" булдыру һәм конкурс оештыру да күздә тотыла. Үзеңне ботаника бакчасында кебек хис итү башны яхшы эшләтүгә һәм дә сәламәтлеккә зур йогынты ясаганы һәркемгә мәгълүм бит инде. Бигрәк тә бездәй язу белән шөгыльләнүче, иҗади дөнья киңлекләрендә хезмәт итүче илаһи хезмәткәрләргә! Шул исәптән, үзебезнең мисалда, илебез куәтенә армый-талмый көч куючы барлык хезмәт ияләренә уңышлар телибез! "Сәламәт тәндә – сәламәт акыл!"

Иҗади коллектив исеменнән – бер төркем.



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 5 (1930) май 2023

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, РТ, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.05.2023 ел.
Тираж – 2575 Заказ С-1053


Редакциянең адресы: 420066, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Нәрсә ул картлык?
2. "Пациент" дигән рус сүзе нишләп кулланыштан төшеп кала язган?
3. Этнең кешедән аермалыгы нәрсәдә?
4. Ир кеше үзенең ятактагы булдыксызлыгын кайчан төшенә?
5. Кем ул банкир?
6. Яхшы тәрбия нәрсәдә ул?
7. Каты халәттән суга әйләнмичә, газга әверелүче матдә ничек дип атала?

ЖАВАПЛАР

1. Элегрәк рәхәтлек биргән кайбер әгъзалар киеренкелек тудыра башласа, картлык шул була. 2. Чөнки түләүсез эшли дип аталган дәваханәләрдә барысы да сау-сәламәт, ә түләүлеләрдә клиентлар гына дәвалана. 3. Аерма шунда – эт асрасаң, аны ашату һәм иркәләү җитә, шуңа күрә ул сине тешләми. 4. Акчасы беткәч. 5. Сиңа җәймә хәтле кулъяулык биреп тора да, одеяло тышлыгы хәтлесен таләп итә. 6. Башкаларның начар тәрбиясенә чыдый алу сәләте. 7. Борчак.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 4 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«ОНЫТА АЛМАСАМ, НИШЛӘРМЕН»**


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас),
А. УМЯРОВА (Мәскәү).

Җиңүчебез – Мәскәүдән
Алсу УМЯРОВА!

Олимпиада елмаюлары

Михаил ЛАРИЧЕВ



Валентин ДУБИНИН




Валентин ДРУЖИНИН



Виктор ФЁДОРОВ



Игорь КИЙКО



Александр АЛЁШИН

